**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 179-43 «16» июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белә расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 23 декабрендәге 98-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы , Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 12 маенда чыккан ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәр Советы карар итте

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белә расланган (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай

шәһәре» муниципаль берәмлегенең  җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, А.Вәлиханов урамы, 5А йорт адресы буенча урнашкан 16:44:01028:167 кадастр номерлы, 1158 кв.метрлы  җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге Д1-шәхси торак йортлар төзү Ж1 зонасына үзгәртергә.

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Әлмәт тракты, 20В йорт адресы буенча урнашкан 957 кв.м мәйданлы 16:44:0000:487 кадастр номерлы булган җир кишәрлеге өчен, П4 куркынычлыгының V класслы җитештерү-коммуналь объектлары зонасыннан, Ж1 шәхси торак йортлар төзү зонасына П4 куркынычлылык зонасыннан территориаль зонага үзгәртергә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай шәһәр Советыныңторак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин